СОВЕТ
МАЛОЦИЛЬНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЕЧЕ ЧЫНЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Тел.: (84375) 39-3-35; 39-4-72, факс: (84375) 39-3-35, e-mail: Mcel.Drz@tatar.ru,

**РЕШЕНИЕ** *с.Малая Цильна* **КАРАР**

2021 нче елның 29 нчы октябре № 11/1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе Конституция судының 19.04.20021 ел, № 14-П карары нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге Советының 2017 елның 20 сентябрендәге 18/1 номерлы карары (2018 елның 27 мартындагы 27/1 номерлы редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләренең 135.13 пунктына " тиешле тәртиптә оешкан һәм дәүләт кадастр исәбенә куелган җир кишәрлекләре милекчеләреннән тыш һәм әгәр бу Россия Федерациясе законнарында каралган мәҗбүри таләпләрне бозмаса;" сүзләрен өстәп үзгәреш кертергә.
2. Әлеге карар Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртип нигезендә махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Кече Чынлы авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртип нигезендә махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кече Чынлы авыл җирлеге башлыгына йөкләргә .

Кече Чынлы авыл җирлеге башлыгы: Г.Ш.Халитов